Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

2021 елның 28 октябре № 25

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Янил авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Янил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 нче пунктны өстәргә:
«17) алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;

1.2. 22 статьяда:
а) 3.1 өлешендә «анда торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы катнашканда» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлешен)» сүзләрен өстәргә.
б) түбәндәге эчтәлекле 3.2 өлешен өстәргә:
«3.2. Торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены җирлек составына керә торган торак пункт территориясе өлешендә үткәрелергә мөмкин.
Мондый гражданнар җыены авыл җирлеге Советы тарафыннан, кимендә 10 кешеле торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче халык төркеме инициативасы буенча чакырыла.
Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре җирлек Советы карары белән торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә гомуми мәнфәгатьләре критерийларыннан чыгып билгеләнә.»;
1.3. 40 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия

Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»

1.4. 46 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»

1.5. 49 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«- алкоголь, наркотик яки башка токсик исереклек халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.»

1.6. 79 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзацны өстәргә:

«Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларда;»;

1.7. 88 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек Уставы, җирлек Советының җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә. Авыл җирлеге башлыгы теркәлгән уставны, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставы турында, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү хакында «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган хәбәрнамә кергән көннән соң җиде көн эчендә бастырырга (халыкка җиткерергә) бурычлы».»

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы И. Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893